СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.05.2023 с. Сарманово № 137

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 27 февралендәге 27-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Сарман муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Сарман муниципаль районы Советы карары проектын (1 нче кушымта) килештерегә һәм ачык тыңлауларга чыгарырга.

2. Расларга:

– Сарман муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе (2 нче кушымта);

– Сарман муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе (3 нче кушымта).

3. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Сарман муниципаль районы Советы карары проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

1. Камалетдинов И. Н. - төркем җитәкчесе;

2. Гыйльфанов Ф. М. – төркем әгъзасы;

3. Юнысов И. М. – төркем әгъзасы;

4. Сәхбиева Г. Г. - төркем әгъзасы;

5) Гайсин Р. М. - төркем әгъзасы

4. Сарман муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча ачык тыңлауларны 2023 елның 30 июнендә 14.00 сәгатьтә Татарстан